Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№18 (69)

30 май 2013 ел

12+

## • Вакыйгалар эзеннән

27 май көнне ректор **ИЛШАТ ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм КФУда якын арада булачак чаралар турында мәгълүмат бирде. И.Гафуров 23 май көнне «Бердәм Россия» Татарстан төбәк бүлеге лидеры, ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин белән килешү төзелгәнлеген әйтте. Әлеге килешү нигезендә Казан федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә итү югары мәктәбе «Идел – Гражданлык университеты» проектын гамәлгә ашыру базасына әйләнәчәк. Бу проект бөтен партияләр өчен дә ачык булачак. Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты җитәкчесе **Р.ЛАТЫЙПОВ** КФУның үсеш программасы күрсәткечләренә туры китереп, институтның ике еллык эшчәнлеге белән таныштырды. Әлеге институт куелган таләпләрне үтәп кенә калмыйча, мәгариф программаларын һәм электрон мәгариф ресурсларнын булдыру, фәнни журналларда басылу буенча күрсәткечләрне уздыра икән. Тел институтының эшчәнлеге турында аның директоры **Т.ИВАНОВА** сөйләде. Утырыш барышында уку дисциплиналарын ныгыту һәм университет эшчәнлегенә кагылышлы башка мәсьәләләр да каралды.

• • • •

19-26 май көннәрендә Литваның Каунас шәһәрендә пауэрлифтинг буенча **ДӨНЬЯ БЕРЕНЧЕЛЕГЕ** узды. Россия җыелма командасы составында КФУның Алабуга институты физика-математика факультеты студенты **АНАСТАСИЯ КУЛИКОВА** да чыгыш ясады. Ул 43 килограммга кадәрге категориядә көмеш медаль яулады.

• • • •

Шушы көннәрдә КФУның Яр Чаллы институтында III **«КЛЮФ»** кыскаметражлы **КИНО ФЕСТИВАЛЕ** тәмамланды. Быел анда 85 кино төшерергә яратучы һәвәскәр катнашты.

• • • •

Күптән түгел Казанда **«УМНИК» КОНКУРСЫНЫҢ ФИНАЛЫ** узды. Әлеге конкурс фәнни-техник өлкәдә кече форма предприятиеләрне үстерүгә булышлык күрсәтү фонды тарафыннан оештырыла. Быелгы финалга 73 катнашучы үткән. Шуның 22се җиңүгә иреште. КФУның Яр Чаллы филиалы студентлары Дарья Русакова һәм Илдар Мәрданов та җиңүчеләр исемлегендә.

• • • •

«Изге Болгар җыены» кысаларында **БОЛГАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ МУЗЕЕ** ачылды. Яңа объектны ачуда Татарстан Президенты Р.Миңнеханов, ТР Дәүләт киңәшчесе М.Шәймиев, Россиянең Диния нәзарәте лидерлары, КФУ ректоры И.Гафуров, республикабызның эшлекле һәм иҗади элитасы вәкилләре катнашты. Музей экспозициясенә беренче экскурсияне КФУның тарих институты директоры Р.Хәйретдинов үткәрде.


• • • •

28 май көнне Казан шәһәре мэры, КФУның юрфагында укыган **И.МЕТШИН** үзе белем алган факультетының **КАЙГЫРТУЧАНЛЫК СОВЕТЫ УТЫРЫШЫН** үткәрде. Анда Казанның район администрацияләрендә түләүсез «юридик клиника»ларының санын артыру турында сүз барды. Әлеге «клиникаларда» КФУның юридик факультет студентлары эшләячәк һәм кешеләргә ярдәм итәчәк. Утырыш азагында И.Метшин факультетка үзеннән бүләк – спорт формаларын сатып алу өчен 467 мең сум акча тапшырды. Алай гына да түгел, мэр юрфакның иң актив студентларының исемлеген әзерләргә кушты. Ул студентларга Универсиада ачылышына һәм ябылышына билетлар биреләчәк.

• • • •

Бүген КФУда Санкт-Петербург дәүләт университетының системалы программалаштыру кафедрасы җитәкчесе, IT-компанияләр рәте генераль директоры, профессор **АНДРЕЙ ТЕРЕХОВ** чыгыш ясады. Танылган галим һәм IT-эшмәкәр Россиядә IT-белем алуның киләчәге һәм бүгенге халәте турында мәгълүмат бирде.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Диана Поварова фотосы

# Рәхәт чак!

«Күңел күзе белән маңгай күзенең бер фокуста очрашкан чагы: бер мизгелдә кояшлы көн, җете яшеллек, яз сафлыгы – яшәү рәхәтен тоеп аласың. Мондый халәт озак булмый, әмма җанда җылысы кала», – дип язган Шәүкәт Галиев май ае турында. Быелгы май Казаныбыз өчен башкачарак килде. Ул елдагыча студентлар тавышыннан шау-гөр килеп тормый. Уку йортлары тирәләрендә китаплар укып, язган лекцияләрне кабатлап, зачет-имтиханнарга керергә куркып утыручы студентлар да юк. Кайсы кая таралган. Кемдер рәхәтләнеп туган авылында, әти-әнисе янында ял итә, кемдер шәһәрдә калып, бераз кесәне калынайту ягын карый, икенчеләре исә, зарыгып, Универсиада башлануын көтә: кемдер волонтер, кемдер Татарстан данын яклауы спортчы... Ничек кенә булмасын, без барыбыз да бер: шат күңелле, актив, позитив замана студентлары! Казан федераль университеты студентлары!

## • Сәяхәттән кайткач

# Яшәсәк тә төрле җирләрдә

**Алисә ФӘРЗИЕВА,**
татар филологиясе бүлеге

Югары уку йортлары арасындагы элемтәләр ныгып кына тора. Шушы көннәрдә Алтай республикасының башкаласы Таулы Алтайда (Горно-Алтайск) узган Бөтенроссия студентлар олимпиадасында катнашкан бер төркем студентларыбыз моңа тагын бер тапкыр инанып кайттылар.

Таулы Алтай дәүләт университеты әлеге олимпиаданы быел җиденче тапкыр оештырды. Төрки телләре һәм әдәбияты, фольклоры буенча үткәрелә торган бу сынауның нәкъ менә Алтайда уздырылуы да юкка гына түгел. Билгеле булганча, төрки халыкларның беренче бабаларының борынгы Ватаны – Алтай.

Быелгы сынауларда Казан (Идел буе) федераль университетыннан беренчеләрдән булып Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлегендә белем алучы III–IV курс студентлары катнашты. 5 кешелек команданың җитәкчесе итеп татар теле тарихы һәм төрки тел белеме кафедрасы доценты **Кадыйрова Энҗе Хәнәфи** кызы билгеләнде. Олимпиадада Татарстан, Башкортстан, Тува, Хакасия, Якутия, Алтай республикаларыннан 9 команда катнашты. Жюри әгъзалары искәртүенчә, быелгы биремнәр Дәүләт стандартлары нигезендә эшләнгән иде. Беренче карашка җиңел генә булып тоелган биремнәр студентлардан күп көч, тырышлык һәм игътибарлылык таләп итте.

Таулы Алтай дәүләт университетының алтаистика һәм тюркология кафедрасы укытучылары студентларга ял программасын төзүгә дә зур игътибар биргән. Олимпиададан соң барлык командалар өчен А.В.Анохин исемендәге Милли музейга экскурсия оештырылды. Шул ук көнне кичен, командаларны бер-берсе белән якыннанрак таныштыру максатыннан, сәламләү өлеше булды. Делегацияләрнең чыгышлары Алтай студентларының музыкаль бүләкләре белән үрелеп барды. Икенче көнне төрки әдәбият һәм фольклор буенча көч сынашкач, Таулы Алтай шәһәрендәге иң биек (641 м) тауга мендек. Шулай ук Алтайның Милли театры тарафыннан сәхнәләштерелгән «Комнар арасындагы хатын-кыз» исемле спектакльне карадык. Шулай ук Чемал районына экскурсия оештырылды. Танылган рәссам, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе Г.И.Чорос-Гуркин музее белән дә таныштык.

**Ахыры 2нче биттә.**



• Хатирә

# «...Чәчәк телле галимә»

*(Р.Сибат)*

**Динара МИННЕКАЕВА,** хәбәрче

Шушы көннәрдә Филология һәм сәнгать институтында татар халкының танылган галимәсе, профессор, барлык студентларның яраткан Остазы Флера Садри кызы Сафиуллинаны искә алдылар.

Кызганыч, бөтен дөньяга танылган, язган фәнни хезмәтләре, китаплары ярдәмендә күпме кешегә белем-тәрбия биргән Флера апа Сафиуллинаның лекцияләрен тыңларга, семинарларында катнашырга, зачет-имтиханнар тапшырырга насыйп булмады. Ләкин мәктәп елларында ук дәресләргә, олимпиадаларга әзерләнгәндә, гел аның китапларына мөрәҗәгать итә, алар ярдәмендә белемемне арттыра идем. Югары уку йортын тәмамлап, эшли башлагач та, гел аның китаплары ярдәмендә үз өстемдә эшләвемне дәвам итәм.

Әгәр исән булса, Флера Сафиуллинага 24 майда 75 яшь тулган булыр иде. Ул элеккеге Сарман, хәзерге Тукай районы Теләнче Тамак авылында туа. Башлангыч белемне татар телендә, урта белемне рус телендә ала. Мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлап, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Бу чорда татар теле кафедрасын филология фәннәре докторы, профессор, академик Мирфатыйх Зәкиев җитәкли торган була. Укучысы турында истәлекләрен Мирфатыйх абый зур сагыну хисләре белән сөйли: «Мин аны беренче курска укырга алдым. Флера башкалардан артык җаваплы, максатчан булуы, рус телен яхшы белүе белән аерылып тора иде. Соңрак инде без аңа Флера Садриевна дип эндәшә башладык, чөнки ул бик тиз арада үсеп җитте. Өченче курста үз кафедрама лаборант итеп эшкә алдым. Шуннан ул бөтен җаны белән фәнгә бирелде. Үземә аспирантурага калдырдым, кандидатлык диссертациясен бик уңышлы яклады. Ун елдан соң, докторлык диссертациясен дә тәкъдим итте. Ул үзен хезмәтләре белән мәңгелеккә язып куйды. 200дән артык китап, 500дән артык фәнни мәкаләләр авторы татар халкы өчен бик күп шәхесләр тәрбияләде. Аларны мин үземнең оныкларым дип саныйм. Ни кызганыч, иң яраткан, хөрмәт иткән укучымның арадан китүе белән килешергә туры килә».

Галимә 1992 елдан университетта яңа – «Чит телдә сөйләшә торган аудиториядә татар теле» кафедрасын җитәкләгән. Ул соңгы елларда җәмгыятебездә булып узган тирән үзгәрешләр нәтиҗәсендә барлыкка килә, республикабызда Телләр турындагы дәүләт программасын гамәлгә ашыру омтылышы белән яши. Аның максаты – яшәешебезнең төрле өлкәләрендә татар телен рус теле дәрәҗәсендә куллана алырдай югары квалификацияле белгечләр әзерләү. Флера апа татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кертү юнәлешендә эшли. Кафедрага чит илләрдән дә татар телен өйрәнергә килүчеләр күп була.

Флера апаның остазы әйтүенчә, ул парлы сүзләр буенча сүзлек әзерли башлаган, ләкин азагына кадәр эшләп җитешә алмаган. Мирфатыйх абый укучыларыннан шул хезмәтне тәмамлауларын үтенде.



Филология һәм сәнгать институты директоры, профессор Рәдиф Җамалетдинов та Флера Сафиуллина турында бик матур хатирәләре белән уртаклашты. Бу көнне алар Флера апаның каберен дә зират кылганнар. «Хәзер без Флера Садрый кызының укучылары белән бер коллективта эшлибез. Алар ул башлаган эшне бик югары дәрәҗәдә дәвам итәләр. Флера апа – үзе генә тулы бер институт эшләрдәй хезмәтләрне башкарган шәхес», – диде Рәдиф Җамалетдинов.

> *Татар теле дигәндә, ул һәрвакыт үз-үзен җәлләмичә, аямыйча яшәде. Ул математиклар белән филологларны дуслаштырып, бергә эшләргә өйрәтеп калдырды. Флера апа дигәндә, елгага төшкән диңгез дулкыны күз алдына килә. Аның тормышы шундый иде: ул, ярларга сыймыйча, диңгез дулкыны булып яшәде. Ул мәңге безнең күңелебездә.*
>
> ТР Фәннәр академиясе вице-президенты, галим Җәүдәт Сөләйманов

Төркемдәшләре сөйләгәннәрне күз яшьләрсез тыңлап та булмады. Алар һәркайсы Флера апа турында җылы, матур сүзләр генә сөйләде. Кемдер аны эш аты, дип атады. Кемдер татар теленең бөтен өлкәләрен дә белгәне өчен хөрмәт итүен әйтте. Алар чыгышыннан Флера апаның оста спортчы: йөзүче, йөгерүче һәм чаңгычы икәнен белдек. Хөрмәтле укытучым, доцент Роза Асылгәрәева да үз хатирәләре белән уртаклашты: «Флера безнең уку йортында (Казан дәүләт педагогия институты – авт.) профессорлык дәрәҗәсен алды. Ләкин ул аның өчен генә килмәде, безнең студентларга төпле белем бирде. Ул беркайчан университетларны аермады. Алай гына да түгел, ике уку йортының студентларын да ул үзенеке кебек якын итте. Флераның тагын бик яхшы оештыручы икәнен әйтеп узарга телим», – диде. Ә профессор Чулпан Харисова якты киләчәк турында хыялланып: «Әгәр кайчан да булса Тел белеме институты ачылса, аңа Флера Садрый кызы Сафиуллина исемен бирсәләр, бик дөрес булыр иде», – диде.

Кем белә, бәлки хыяллар чынга ашар. Бу көнне аның күпмедер өлеше чынга ашты дияргә дә мөмкин, чөнки Филология һәм сәнгать институты коллективы бер кабинетка галимә Флера Садрый кызы Сафиуллина исемен бирергә карар кылды.

Чарада катнашучы һәр кеше тарафыннан яңгыраган сүзләрне минем дә кабатлыйсым килә: «Тыныч йоклагыз, Флера апа. Без Сезне онытмабыз!»

• Абитуриентлар өчен

# Фәлсәфә факультетында яңа юнәлеш!

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Бу уку елында КФУның Фәлсәфә факультетында өр-яңа «Теология» юнәлеше ачыла.



Моның үз сәбәпләре дә бар. 1797 елдан бирле үк Казанда Дини Академия эшләп килгән. Биредә Россиянең иң күренекле фәлсәфәчеләре һәм теологлары укыткан. Бу уңайдан Виктор Иванович Несмелов исемен генә дә телгә алу җитә. Революциядән соңгы чорда, хакимият карары аркасында гына, Академияне Казан университетының бер факультеты итеп үзгәртеп кора алмый калалар. Теологиянең теоретик компоненты, дини тәгълиматны, системалы рәвештә дингә ышанучылар тарафыннан бәхәскә җирлек калдырмый торган төп кануннарны, гыйбадәт кылу һәм йола үзенчәлекләрен өйрәнү белән бәйләнгән. Фәлсәфи яктан әзерлеккә зур урын бирелә, чөнки фәлсәфә озак вакытлар теология белән янәшә, хәтта аның аерылмас өлеше итеп карала.

Заманалар үзгәрә, әмма бүген, кешеләр акча колына әйләнеп барган заманда, рухи кыйммәтләр аеруча мөһим. Өстәвенә гуманитар белгечләргә сорау да көннән-көн үсә бара. Берәү дә теологияне фән буларак танырга мәҗбүр итми: бу һәркемнең үз эше. Биредә теологияне әзерлекнең бер юнәлеше итеп карау дөресрәк булыр. Аның төп максаты дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр өлкәсендә дини оешма һәм дәүләт органнары арасындагы үзара тәэсир итешү, йогынтыны көйләүче белгечләр әзерләү булачак. Теологның практик эшчәнлеге нәкъ менә шуңа юнәлдереләчәк. Бу уңайдан аңа гомумһөнәри дисциплиналарны дини хокук юнәлешенә бәйләп өйрәнү ярдәмгә киләчәк. Мисал өчен, «Хаҗ хезмәтен оештыру» дисциплинасы практик яктан чит телләр (мәсәлән, гарәп теле) һәм дини культура куллануны таләп итәчәк.

Фәлсәфә факультеты бакалавриатында ислам һәм христиан диннәре юнәлеше буенча «Дәүләти-конфессиональ мөнәсәбәтләр» белгечлеге ачыла. Магистратура профиле исә, «Фән һәм дин» дип аталачак. Бу юнәлештә белем алучылар барлык фәннәрне һәм теологик мәсьәләләрне үзара бәйләнештә җентекләп өйрәнәчәк.

• Чара

28 май көнне КФУда ректор Илшат Гафуров җитәкчелегендә чираттагы Гыйльми совет узды.

# Тәкъдимнәр кабул ителде

Утырыш Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры, профессор, техник фәннәр докторы **Р.Латыйповны** 60 яшьлек юбилее белән котлаудан башланып китте. Юбилярга күпьеллык һәм нәтиҗәле эшчәнлеге, Казан университеты үсешенә керткән өлеше өчен ректорның рәхмәт хаты тапшырылды.

Аннан соң, көн тәртибендәгечә, кафедра җитәкчеләрен, профессор, баш фәнни хезмәткәр, Физик тәрбия һәм спорт кафедрасы доценты вазифасына сайлаулар булды.

Чарада КФУның Мәгълүматлаштыру һәм элемтә департаментының төп эшчәнлек юнәлешләре бедән департамент директоры **Д.Бурмистров** таныштырды. Ул телекоммуникация инфраструктурасын модернизацияләү һәм IT-хезмәтләр үсешенә булышлык күрсәтү, «Электрон университет» мәйданчыгы өстендә эшләү, яңа җиһазлар белән тәэмин ителеш мәсьәләләренә тукталды. Д.Бурмистровның чыгышыннан соң, ректор **И.Гафуров** департаментка, беренче чиратта, университетның әйдәп бара торган институтларындагы мәсьәләләрне хәл итә торган приоритетларны билгеләргә киңәш итте.

Академик комиссия рәисе **Д.Таюрский** Гыйльми совет алдына түбәндәге тәкъдимүтенеч белән чыкты: Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтында экспедицион эшләр һәм шәһәр читендәге базалар үзәген ачарга; Алабуга институтының хокук һәм икътисад кафедрасын үзгәртеп корырга; Санкт-Петербург дәүләт университеты һәм Икътисади университет (Вроцлав шәһәре) белән берлектә, КФУның Икътисад һәм финанс институтында «Банклар һәм реаль икътисад» исемле халыкара һөнәри магистрлык программасын булдырырга. Гыйльми совет академик комиссиянең тәкъдимнәрен яклап чыкты.

Ахырда Гыйльми совет Казан университеты хезмәткәрләренә республика һәм федераль дәрәҗәдәге мактаулы исемнәр бирү мәсьәләсен тавышка куйды. Кайбер студентлар һәм аспирантлар төрле стипендияләргә тәкъдим ителде.

• Сәяхәттән кайткач

# Яшәсәк тә төрле җирләрдә

**Башы 1нче биттә.**

Олимпиада белән параллель рәвештә, студентлар арасында фәнни проектлар конкурсы да үткәрелде. Татар филологиясе бүлеге студентлары, Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еники, Рабит Батулла һәм башка әдипләребезнең татар телендәге һәм төрекчәгә, русчага тәрҗемәләрен төрле аспектларда тикшереп, кызыклы материалларга бай булган эшләр белән катнашты. Уңышларыбыз да мактанырлык: диплом-грамоталар белән бүләкләндек. Гомумән алганда, Казан командасы әлеге олимпиададан бик канәгать калды.

Олимпиаданы оештыручыларга барлык катнашучылар исеменнән зур рәхмәтләребезне җиткереп, мондый очрашулар киләчәктә дә дәвам итсен һәм зуррак географияне иңләсен иде дигән теләктә калабыз. Шушындый мәртәбәле ярышларда катнашу өчен, мөмкинлекләр тудырулары, студентларының уңышларына ышанып, җан атып торулары өчен, университет, институт һәм татар филологиясе бүлеге җитәкчелегенә зур рәхмәтләребезне җиткерәбез!

● Мөнбәр

## Динә Гарипова: «Нәтиҗәдән канәгатьмен!»

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Күптән түгел Швециянең Мальме шәһәрендә узган «Евровидение – 2013» җыр конкурсында милләттәшебез, КФУ студенты, Татарстанның атказанган артисты Динә Гарипова 5 урынга лаек булган иде. Бәйге үткәннән соң, Динә Татарстанга кайтты һәм безнең редакциягә дә кереп чыкты. Без, үз чиратыбызда, аңа сорауларыбызны ирештердек.

**– Динә, сине «Евровидение»дәге уңышлы чыгышың белән котлыйбыз! Син Европаның иң яхшы җырчылар бишлегенә кердең. Синең өчен бу конкурста иң авыры нәрсә булды?**

– Беренчедән, котлавыгыз өчен бик зур рәхмәт. Минем өчен бәйге артык авыр булмады. Конкурс бары тик уңай кичерешләр калдырды. Яңа танышулар, яңа дуслар табуыма сөенәм.

**– «Евровидение»дә нинди атмосфера хөкем сөрде?**

– Андагы атмосфера бик позитив, дустанә, чөнки халык чыннан да бик әйбәт кабул итте.

**– «Евровидение» конкурсы еш кына бәхәсле шау-шулар белән уза. Быелгы конкурс та искәрмә булмады. Синеңчә, хөкемдарлар гадел идеме?**

– Мин беркайчан да үземне бәяләүчеләрне хөкем итә алмас идем. Һәр кешенең үз вазифасы. Мин мондый бәхәсгаугалардан бик ерак. Үз чыгышымнан һәм соңгы нәтиҗәдән канәгатьмен. Минемчә, беренче бишлеккә керү – бик шәп. Шуның өчен берәүгә дә үпкәдәгъвам юк.

**– «Евровидение»дә чыгыш ясау – зур казаныш. Киләчәккә нинди иҗади планнарың бар?**

– Планнар бихисап, әлбәттә. Хәзер минем өчен иң мөһиме – альбом яздыру.

**– Ә иҗади булмаган планнарың? Әти-әниең янына кайтырга җыенасыңмы?**

– Әлбәттә! Әлегә мине вакытлыча ялга җибәрделәр. Ул вакытны якыннарым белән уздырырга ниятлим.

**– Динә, сине хәзер бөтен ил күзәтә. Халык хәтта синең нинди күлмәк кигәнең белән дә кызыксына. «Нәрсә һәм ничек кияргә?» дигән сорауга җавапны сиңа атаклы Эвелина Хромченко табышты. Үзара мөнәсәбәтләрегез ничегрәк иде?**

– Без үзара бик әйбәт мөнәсәбәттә. Мин әлеге шәхес белән танышуыма бик шат. Ул, чыннан да, нәрсәне һәм ничек кияргә икәнлекне белә. Эвелина миңа төпле киңәшләрен бирде. Евровидение алдыннан кирәкле күлмәкне эзләп табар өчен вакытыбыз артык күп түгел иде, кызганыч. Шулай да ул миңа бик күп вариантлар тәкъдим итте. Ахыр чиктә мин чыгыш ясаган күлмәкне Норвегия дизайнеры текте.

**– Күпчелек шоу-бизнес йолдызлары үзенең тышкы кыяфәтенә зур игътибар бирә, спорт белән шөгыльләнә. Синеңчә, артист өчен буй-сынмы, әллә тавыш мөһимрәкме?**

– Әлбәттә, әгәр син артист-вокалчы икән, димәк, син җырларга тиеш. Шуңа да бу очракта тавышың булу – иң мөһиме. Әмма, шул ук вакытта, син сәхнәдә матур күренергә дә тиеш. Бу стандарт, калыпка салынган образда чыгыш ясау дигән сүз түгел, әлбәттә. Һәрчак үзең булып кала белү һәм үзеңә якын образга тугры калу кирәк.

**– Татар сәхнәсендәге кайсы җырчыларны яратып тыңлыйсың?**

– Мин Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Венера Ганиева, Габделфәт Сафин иҗатларын яратам һәм хөрмәт итәм.

**– Белүебезчә, син КФУның Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты студенты. Киләчәктә журналист булып китәргә ниятең бармы?**

– Моңа кадәр миңа төрле газеталарда басылырга туры килде. Бәлки, киләчәктә бу өлкәдә дә эшләрмен дигән уйлар белән яшим.

**– Тамашачы синең шәхси тормышың белән дә кызыксына. Әйт әле, илебезнең иң күренекле кызының йөрәге яуланганмы инде? Синең өчен идеал бармы?**

– Шәхси тормыш шуның өчен дә шәхси бит инде ул... Әлбәттә, кызыксыну барлыгын аңлыйм. Әмма мин иң беренче чиратта җырчы. Шуңа да шәхси тормышымнан бигрәк иҗатым белән күбрәк кызыксынуларын теләр идем. Идеалларга килгәндә, идеаль кешеләр юк, дип саныйм.

**– КФУ студентлары, хезмәткәрләре зур дулкынлану белән чыгышыңны күзәтте, синең өчен җан атты. Аларга нинди теләкләрең бар?**

– Аларга чын күңелемнән рәхмәтемне белдерәм. Конкурс вакытында туган университетымның җан атуын тою минем өчен зур таяныч булды. Барыгызга да уңышлар, үз-үзегезгә ышаныч телим! Киләчәктәге иҗади казанышларым да сезне сөендерер дигән өметтә калам!

– Әңгәмәң һәм матур теләкләрең өчен рәхмәт, Динә!

## «Евровидение» турында




✓ Евровидение бәйгесе 1956 елдан бирле уздырыла һәм ул дөньядагы спортка кагылышы булмаган чараларның иң популяры булып санала. Хәзер аны йөздән алып, алты йөз миллионга кадәр кеше карый.

✓ Җыр 3 минуттан да артырга тиеш түгел. 1999 елга кадәр җыр катнашкан илнең дәүләт телендә генә башкарылырга тиеш булган. Хәзер исә җырчы аны теләгән телдә башкара ала.

✓ Белгечләр Евровидениедә башкарылган җырларның күпчелеге мәхәббәт турында булганлыгын әйтә. Соңгы арада җырларның өчтән икесе инглиз яисә француз телендә башкарыла. Бу ике тел, уңышка ирешү өчен, иң кулай телләр дип исәпләнә.

✓ Россия Евровидениедә 1994 елдан бирле катнаша һәм 12 тапкыр финалда катнашкач, 2008 елда беренче урын яулый.

✓ Бүгенге көндә Россиядән Евровидениедә иң яхшы күрсәткечкә ирешкән җырчы – Дима Билан. Ул 2008 елда «Believe me» җыры белән 272 балл җыеп, беренче урынга чыкты. Ә иң түбән нәтиҗә күрсәтүчеләр: «Колыбельная для вулкана» җыры белән 17 балл җыйган Филипп Киркоров (17 урын) һәм «Примадонна» җыры белән 33 балл җыйган Алла Пугачева (15 урын).

✓ 2000 елда Россиядән Бөгелмә кызы Алсу Сафина катнаша һәм «Solo» җыры белән икенче урынга (155 балл) лаек дип табыла. Бу Россиянең беренче тапкыр шундый югары урын яулавы була.

● Белем баскычлары

## Яңа перспективалар

**Алинә САДЫЙКОВА,** хәбәрче

28 май көнне «КФУда дистанцион укыту технологияләре: проблемалар һәм аларны чишү юллары» темасына түгәрәк өстәл узды.

Без югары технологияләр заманында яшибез, шуңа күрә университетта дистанцион укыту эшләре дә алып барыла. Моның өчен КФУның шактый бай материаль базасы бар. Бездә дистанцион укыту процессы әлегә катнаш формада гамәлгә ашырыла. Мисал өчен, студентлар лекцияне электрон рәвештә алып, аны укып, эшкәртәләр, ә укытучы белән мөһим булган яисә авыр тоелган урыннарны әңгәмә, консультация рәвешендә үзләштерәләр.



Диана Поварова фотосы

Мондый очракта студентларга мөстәкыйль эшләргә мөмкинлекләр булдырыла, дип исәпли белгечләр. «Без студентлар һәм укытучылар өчен яңа перспективалар булдырырга телибез. Бүген технологияләр мондый мөмкинлек тудыра ала. Әзер электрон ресурсларны электрон китапханәдә дә булдырырга кирәк. Әгәр шулай эшләмәсәк, нәтиҗәләр түбән булачак. Болай да вакыттан артта калабыз», – диде уку-укыту эшләре буенча проректор **Рияз Минзарипов**.

Чарада бу өлкә белгечләре: КФУның дистанцион укытуны оештыру бүлеге җитәкчесе Виктория Устюгова һәм дистанцион укыту үзәге директоры Ольга Кашиналар да катнашты. Н.И.Лобачевский ис. фәнни китапханә директоры Евгений Струков «КФУның электрон типографиясе: куллану практикасы» темасына чыгыш ясады: «Басма формадан электронга күчәр вакыт җитте. Безнең әле тәҗрибә зур түгел, шуңа күрә бергә хәл итәсе мәсьәләләр күп. Әйтик, электрон материалның сыйфатын ничек билгеләргә, материаллар ачык вариантта ни дәрәҗәдә булыр, студент һәм укытучыларны ни рәвешле регистрацияләргә, кирәкле мәгълүматка тап булу юлларын ничек булдырырга һәм башкалар. Шунысы төгәл билгеле: студентларга электрон материаллар белән танышу өчен рөхсәт булачак, ә менә басма вариантны үзләштерергә теләүчеләр аны сатып алачак». Алай гына да түгел, киләчәктә китапханә дә шул әсбапларны авторларыннан сатып алачак.


Электрон китапханәне тулыландыру һәм тиешле дәрәҗәдә эшләтү максатыннан, һәр институтның барлык фәннәр буенча да I курслар өчен кыскача лекцияләр конспектларын тупларга кирәк дигән фикергә килделәр. 3 июньгә шул дисциплиналарның исемлеген булдырып, 1 сентябрьгә инде тулысы белән эшкәртеп, тиешле бүлеккә тапшырырга кирәк булачак.

Бу очрашу гадәттәгечә фикер алышу формасында түгел, бераз үзгә форматта уздырылды. Беренче өлештә, чыгышлар ясап, әңгәмә кордылар, икенче өлеш практик рәвештә үтте. Чарада катнашучылар төркемнәргә бүленеп, экспертлар булып, үзләре дистанцион курсларны бәяләп карадылар.

● Яңа китап

## Республикабыз географиясе - белешмәлектә

**Фәрит ГАЙНУТДИНОВ,** Апас районы Чирмешән гомуми урта белем бирү мәктәбенең география укытучысы




И.Т.Гайсин, Р.Р.Динмухәмәтов, О.В.Зявлова авторлыгында нәшер ителгән «Татарстан Республикасы: кыскача географик белешмәлек» дип аталган китап дөнья күрде.

Казан федераль университеты галимнәре төзегән белешмәлектә Татарстан республикасының географик урыны, аның табигый шартлары, халкы, хуҗалык эшчәнлеге тасвирланган. Әлеге хезмәт, республиканың хәзерге көндәге географик үзенчәлекләрен үз эченә туплап, соңгы статистик материалларга таянып төзелгән. Мәгълүмат аңлаешлы һәм тулы.

Яңа китап – «Татарстан Республикасы: кыскача географик белешмәлек» белән танышканнан соң, бу китапның бик вакытлы дөнья күргән, бүгенге укыту системасында алыштыргысыз кулланма материал: эчтәлекле, компактлы хезмәт икәне аңлашыла. Белешмәлектә урын алган материаллар географиянең күп тармакларын үз эченә алганнар. Белешмәлек иллюстратив материалларга бай, алар тирән эчтәлекле, тексттагы мәгълүматны уңышлы тулыландыралар, республиканың матур һәм бай төбәк булуын кабаттан ассызыклыйлар.

Әлеге хезмәт – укытучылар, Татарстанга читтән килүчеләр һәм, гомумән алганда, респуликабыз турында булган белемнәр белән кызыксынган һәркем өчен дә универсаль материал. Белешмәнең татар, рус һәм инглиз телләрендә булуы бик отышлы. Белешмәлек төзүдә электрон чыганаклар актив кулланылган.

Сүзне йомгаклап, шуны әйтергә була: киләчәктә инглиз теле фәне дә БДИ рәвешендә бәяләнәчәк бит, шунлыктан әлеге белешмәлек укучыларда зур кызыксыну уятыр һәм ярдәмлек хезмәтен үтәр дип уйлыйбыз. Белешмәлекнең аны киң кулланырлык сандагы тиражын көтеп калабыз.

• Дуслык күпере

# «Читкә бер барып кайту җитә!»

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

МАЙ АЕНЫҢ ИҢ КЫЗУ ЧАКЛАРЫНДА, СТУДЕНТЛАР, СЕССИЯЛӘРЕН ТӘМАМЛАП, ЯЛ ИТЕП ЯТКАН ВАКЫТТА, УНИВЕРСИТЕТЫБЫЗ МАГИСТРЛАРЫ ҖИҢ СЫЗГАНЫП БЕЛЕМ ЭСТИ.

Күптән түгел Төркия дәүләтенең Караман шәһәрендә төрек телендә сөйләшмәүче студентларның дөньякүләм конференциясе үтте. Анда Филология һәм сәнгать институты татар филологиясе бүлегенең беренче курс магистры Гүзәл Шәмсиева да (*фотода сулда*) катнашып кайтты.

Әлеге конференция икенче тапкыр үткәрелә. Аның төп максаты булып, төрле ил студентларын бергә җыю, таныштыру, аларны аралаштыру һәм тәҗрибә уртаклашу тора. Чарада 500гә якын студент катнашырга теләк белдергән. Оештыручылар шулар арасыннан 55 эшне югары бәяли һәм аларны Төркиянең Караманоглы Мехметбәй университетына чакыра. Бирегә Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Монголиядән килгәннәр, Татарстанны исә безнең Гүзәл тәкъдим итте.

Конференциянең тематикасы әдәбият һәм тел тармакларының төрле мәсьәләләренә багышлана. Гүзәл Шәмсиева исә «Хәзерге Коръән тәфсирләренең тел үзенчәлекләре» темасын яктыртып чыгыш ясый. «Бу теманы миңа җитәкчем филология фәннәре кандидаты, доцент Энже Хәнәфиевна Кадыйрова бишенче курста укыганда диплом темасы буларак тәкъдим иткән иде. Хәзер аны магистрлык эше буларак дәвам итәм. Энже Хәнәфиевна һәм татар теле тарихы һәм төрки тел белеме кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы, профессор Фәнүзә Шәкуровна Нуриевага фәнни юнәлеш бирүләре һәм күрсәткән ярдәмнәре өчен, чиксез рәхмәтемне белдерәм».



Гүзәлнең Төркиягә һәм, гомумән, чит илгә беренче тапкыр баруы булган. Шуңа да аның тәэсирләре күп һәм төрле: «Әлеге конференциядән һәм чит илдән үзем өчен уйландырырлык нәтиҗәләр белән кайттым. Үзебезнең Казан университетын һәм Караманоглы Мехметбей университетларын чагыштырып йөрдем. Һәр икесенең дә үзенә күрә өстенлекләре барлыгын әйтәсем килә».

Гүзәлне Төркиядә таң калдырган әйберләрнең берсе – җирле халык. Аңа конференция вакытында күп кешеләр белән аралашырга туры килгән. Гүзәлнең сүзләренчә, анда бар кеше дә ачык йөзле, аралашучан, ярдәмчел, аларда һич тә тәкәбберләнү сыйфатын күрмәссең (күпләр бу урында «Безнең халыкка бу сыйфатлар җитеп бетми шул», дип уйлап куйганнардыр). Конференцияне оештыручылар да яхшы каршылап, күңелле итеп шәһәр буенча экскурсиягә, тирә-якның гүзәл җирләре белән таныштырырга алып барган. Гүзәл Төркиядәге дусларыннан бөтен татар башкаласы булган Казанга кайнар сәламнәр дә алып кайткан.

Күп дуслар табып, үзе өчен яңа мәгълүматлар туплап, белем эстәп, матур җирләр күргән магистрыбыз туган ягын бик сагынган. Сагыну хисен шигырь юлларына да салган:

*Чит илләрдә яшәү рәхәт,*
*диләр,*
*Туган җирләр керә төшләргә,*
*Үз илеңдә булу бәхет инде,*
*Читкә бер барып кайту җитә.*

• Студент эш эзли

# Студентның төп эше – уку?

**Илмира АХУНОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

БЕЗ, ЯШЬЛӘРНЕ, КҮПМЕ ГЕНӘ СҮКСӘЛӘР ДӘ, ҖАВАПСЫЗЛЫКТА ГАЕПЛӘСӘЛӘР ДӘ, АРАБЫЗДА БИК ТЫРЫШЛАР ДА БАР. МӘКТӘПНЕ ТӘМАМЛАП, ИНДЕ СТУДЕНТ БУЛГАЧ, ӘТИ-ӘНИ ҖИЛКӘСЕННӘН ТӨШЕП, МӨСТӘКЫЙЛЬ ЯШӘРГӘ ТЫРЫШУЧЫЛАРЫБЫЗ БАЙТАК. УНИВЕРСИТЕТТА КӨНДЕЗГЕ БҮЛЕКТӘ УКЫП ТА, БЕРӘР ҖИРДӘ ЭШЛӘҮЧЕ, ФАТИРЫНА ДА, КИЕМ-САЛЫМЫНА ДА, АЙ БУЕ АШАРГА ДА, ЯЛ ИТӘР ӨЧЕН ДӘ АКЧА ҮЗЕ ЭЗЛӘП ТАБУЧЫ ТАНЫШЛАРЫМ ШАКТЫЙ. АЛАР КӨНЕ БУЕ УКЫРГА ДА, АННАРЫ ЭШКӘ ДӘ БАРЫРГА ӨЛГЕРӘЛӘР.



Хәзер рекламалар басылган кайсы гына гәҗитне алма, интернеттагы сайтны ачма, студентлар өчен махсус графиклы эшләр тәкъдим ителгән. Әлбәттә, кыюлыгы җиткән, эш белән укуны бер үк вакытта алып барам, дип тәвәккәлләгәннәр бик тиз риза була. Бүген стипендиянең күләме бер мең ике йөз сум, кызганыч, бу ай буена шәһәр буйлап автобуста йөрергә генә җитә. Ярар, ашарга әти-әни дә төяп җибәрер. Әле бит аның ял да итәсе, дуслар белән киногa да барасы килә, өстәвенә, төркемдәшенең туган көненә бүләк тә алып барырга кирәк... Кыскасы, студент өчен акча мәсьәләсе көн кадагында тора. Ничек тә укуны калдырмаска, әз-мәз акча да эшләргә тырышабыз. Тик еш кына эше белән бик каты мавыгып китеп, укуын ташлаучылар яки укырга йөри алмау сәбәпле, университеттан «очып чыгучы»лар да була. Көндезге бүлектән читтән торып уку бүлегенә дә күчә күпләр. Нишләтәсең, яшәргә кирәк, акча кирәк...

Икенче яктан карaганда, эшләгән студентның уку сыйфаты да начарая. Төннәрен вагон бушаткан яки машинада «бомбить» итеп йөргән студент иртәнге сигездәге семинар вакытында доклад укырлык дәрәҗәдә булмый инде, аудиториянең соңгы партасында йоклап алу гына аның уенда. Ни дисәң дә, эш укуга комачаулый кебек. Юкка гына, студентның төп эше – уку, дип әйтмиләр. Әлеге сүзләрне күп кенә укытучылардан да ишетергә мөмкин. Алар студентның кайда да булса эшләп йөрүен өнәп бетермиләр. Бер укытучыбыз: «Бер үк вакытта аннан-моннан укып та, эшләп тә университет тәмамлаган студентларыбыз үз һөнәрләре өлкәсендә тиешле дәрәҗәдә профессионал булып җитми. Акча каян алырга икән, берәр җирдә эш юкмы икән, дип уйлап йөргән студентның башында уку кайгысы юк инде аның. Аның вакыты кирәкле фәннәрне дә өстән-өстән генә үзләштерергә генә җитә», – диде. Сүзләрендә хаклык бар...

Бу турыда студент яшьтәшләремнең нәрсә уйлаулары белән дә кызыксынырга булдым.

**• Динар Вәлиев (КФУ студенты):**

Мин үз һөнәрем буенча, ягъни газетада корреспондент булып эшлим. Уку белән эшне берьюлы алып барырга телим. Ләкин кайвакыт авырлыклар килеп чыга. Дәрес вакытында, мәсәлән, тиз арада эшкә чакырырга мөмкиннәр. Киресенчә, бик кызыклы репортажлар ясарга барып булмый, чөнки укуда кыенлыклар туа. Бүгенге стипендиягә, күп дигәндә, бер атна гына яшәргә була. Әгәр дә студент фатирда торса, аның өчен дә икеләтә-өчләтә түләргә кирәк. Моны укытучылар аңламый, чөнки алар укыган вакытта барысы да бушлай бирелә торган булган!

**• Алинә Камалиева (КФУ студенты):**

Беренче курста «Азатлык» радиосында эшләдем. Шул ук вакытта, өстәмә рәвештә хисапчы һәм визажист-стилист белгечлекләренә укып, диплом алдым. Хәзерге вакытта ике җирдә эшлим. Берсе үз эшем – бизәндерү буенча кабул итәм һәм укытам, икенчесе – бер шәхси фирмада исәп-хисап буенча. Журналистиканы ташламыйм һәм ташламадым да, һәрчак язам. Киләчәктә шул өлкәдә эшләргә телим. Ә калган һөнәрләргә килгәндә, минемчә, журналист кеше бик күп белергә, үзен төрле өлкәләрдә сынап карарга тиеш. Эшем укуга бер дә комачауламый. Теләгән кеше барысына да җитешә, өлгерә. Беренчедән шомарасың, күзаллавың киңәя, күп әйбергә өйрәнәсең. Икенчедән, акча ягыннан да кытлык кичермисең.

• Киңәш-табыш

# Талпанның азган чагы

Киңәшче ролендә
**Ләйсән ИСХАКОВА**



Яз - табигать яшәргән вакыт кына түгел, урман бетенең дә активлашкан чоры да. Алар, кешенең тәненә кадалып, вируслы талпан энцефалитын һәм талпан боррелиозын (Лайм авыруы) кузгатучыларны күчерергә мөмкин. Урман-парк зоналарына, шәһәрдән читтә урнашкан ял итү урыннарына, зиратларга барганда, түбәндәге киңәшләрне үтәсәгез, урман бете куркыныч тудырмас.

Талпан булу куркынычы аз маршрутларны сайлагыз. Кояш яктысы төшә торган каен урманнарында алар азрак була, аскы ябалдашлары булмаган нарат урманнарында исә бөтенләй очрамый диярлек.

Урман тирәләренә чыкканда, яка-манжетларны, күлмәкне төймәләргә, свитерны чалбар, чалбар балакларын резин итекләр эченә тыгарга кирәк. Ачык төстәге өс киемнәрендә бөҗәкләр яхшырак күренә.

Өс киемен һәм тәннең ачык урыннарын талпаннарны куркыта торган махсус препаратлар белән эшкәртергә киңәш итәбез.

Урманда яки дача участогында булганда, һәр ике сәгать саен киемнәрне салмыйча гына үзеңне яки иптәшеңне талпаннар булу-булмауга тикшереп торыгыз.

Өйгә кайткач, тышкы өс киемен ишегалдында яки кеше яшәми торган бинада салырга кирәк. Киемнең эчке һәм тышкы ягын карагыз, кесәләрен, җөйләрен яхшылап тикшерегез. Тәннең йонлы, җыерчыклы урыннарына, колак яфракларына һәм култык асларына аеруча игътибар итегез.

Кадалган урман бетен кичекмәстән алырга кирәк. Талпанны алып ташлау буенча квалификацияле медицина ярдәмен алу яхшырак. Андый мөмкинлек булмаса, талпанны, тирегә кадалган өлешен өзмәскә тырышып, тизрәк алырга кирәк. Талпан кадалган урынга 10-15 минутка теләсә нинди май сөртегез, бу аның сулыш алу тишекләрен томалаячак. Аннары талпанны марля уралган бармак белән, бер яктан икенче якка селкеткәләп, җиңел-җиңел хәрәкәтләр белән тартып алырга. Башы өзелеп калса, аны спирт белән эшкәртелгән яки утта кыздырылган энә белән актарып чыгарырга кирәк. Талпан кадалган урынны, аны алганнан соң, спирт, йод яки одеколон белән ышкыгыз. Кулыгызны әйбәтләп сабынлап юыгыз.

Медицина учреждениесенә үз вакытында мөрәҗәгать итү гаять мөһим, чөнки талпанга каршы иммуноглобулин уколын, талпан кадалганнан соң, 4 көннән дә соңга калмый ясатырга кирәк.

Талпан энцефалитыннан саклануның иң ышанычлы чарасы – вакцинация узу. Әгәр дә сез Себер, Урал, Ерак Көнчыгыш федераль округлары, шулай ук күрше Удмуртиягә, Пермь краена, Киров өлкәсенә ял итәргә барырга җыенасыз икән (бу урыннарда талпан энцефалиты йоктыру куркынычы зур), алдан ук вакцинация курсын узуың хәерле. Вакцинация 2 прививкадан тора, алар арасындагы ара 1-2 айдан да артмаска, инфекцияле урынга барырга ике атна кала тәмамланырга тиеш. Талпан боррелиозыннан саклый торган вакцина әлегә чыгарылмаган.

DARELFØNYN университет
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш.,
Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.